| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.07.2025 Казан шәһәре № 132-ОД

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территория-ләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм сәүдә объектының (территориянең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешенә тиешле контрольлекне гамәлгә ашыру максатларында,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен расларга (кушымтада бирелә).

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының
_____________ _____ номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) (алга таба – сәүдә объектлары (территорияләр)) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен милек хокукында, хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү максатларында сәүдә объектларын (территорияләрне) урнаштыру өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә, биналарга, корылмаларга һәм төзелмәләргә ия булган яисә сәүдә объектларын (территорияләрне) урнаштыру өчен җир кишәрлекләреннән, биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан һәм урыннардан башка законлы нигездә файдаланучы юридик һәм (яисә) физик затлар (алга таба – сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе) тарафыннан аларның сәүдә объектларын (территорияләрен) террорчылыктан саклауга һәм элек үткәрелгән тикшерүләр барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүенә карата таләпләрне, тикшерүләр үткәргәндә процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген үтәвенә карата сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр (алга таба – тикшерү) уздыру юлы белән контрольлекне гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Тәртип түбәндәгеләргә нигезләнеп эшләнгән:

– «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга;

– «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законга;

– «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы федераль законга;

– «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы федераль законга;

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм сәүдә

объектының (территориянең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карарына;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 324 номерлы карарына.

1.3. Контроль предметы булып түбәндәгеләр тора:

а) сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклану торышын билгеләү;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм сәүдә объектының (территориянең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары таләпләрен сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе тарафыннан үтәү;

в) элек үткәрелгән тикшерүләр барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү.

1.4. Министрлык сәүдә объектларының (территорияләрнең) террорчылыктан саклануын планлы һәм планнан тыш тикшерүләр оештырган һәм үткәргән өчен вәкаләтле орган булып тора.

## 2. Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздырганда Министрлык вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары

2.1. Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздырганда Министрлык вазыйфаи затларының хокуклары:

а) башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булган тикшерү предметына кагылышлы документларны һәм (яисә) мәгълүматны түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, соратырга һәм алырга;

б) тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектларының (территорияләренең) хокук ияләреннән, аларның вәкаләтле вәкилләренән контрольлекне уздыру өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

в) планлы яисә планнан тыш тикшерү уздыру турында Министрлык боерыгының күчермәсен һәм хезмәт таныклыгын күрсәткәннән соң, тикшерү үткәрелә торган объектларга һәм сәүдә объектларына (территорияләренә) барып, тоткарлыксыз тикшерү үткәрергә;

г) тикшерүләр үткәрү барышында алына торган мәгълүматны теркәү өчен тавыш яздырырга, фотога һәм видеога төшерергә;

д) тикшерү актларын төзергә.

2.2. Тикшерүләр үткәргәндә Министрлык вазыйфаи затларының бурычлары:

а) Россия Федерациясе законнарын, сәүдә объектлары (территорияләр) хокук ияләренең, аларның вәкаләтле вәкилләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

б) тикшерүләр уздыру турындагы боерыклар нигезендә һәм әлеге Тәртип нигезендә тикшерүләр уздырырга;

в) тикшерүләр үткәрүнең билгеләнгән срокларын үтәргә;

г) хезмәт вазыйфаларын башкарган вакытта, хезмәт таныклыгын, аны үткәрү турында Министрлык боерыгының күчермәсен күрсәтеп, күчмә тикшерү рәвешендә тикшерүләр үткәрергә;

д) тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә яисә аның вәкаләтле вәкиленә мәгълүмат һәм документлар бирергә, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

е) тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясен яисә аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре (тикшерү акты) белән таныштырырга, шулай ук аңа кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат җиткерергә;

ж) тикшерү гамәлгә ашырыла торган сәүдә объектының (территориясенең) хокук иясенә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә урынга барып тикшерү рәвешендә катнашырга комачауламаска;

з) тикшерү үткәрү барышында Министрлык тарафыннан алынган коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, ачмаска;

и) тикшерү башкарыла торган сәүдә объектлары (территорияләр) хокук ияләренең, аларның вәкаләтле вәкилләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска.

## 3. Контрольлек нәтиҗәсенә тасвирлама

3.1. Контрольлек нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

а) тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән акт (алга таба – тикшерү акты);

б) хокук бозулар ачыкланган очракта – ачыкланган хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Прокуратурасына һәм Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиягә хәбәр итү рәвешендә чаралар күрү.

## 4. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне оештыруның һәм уздыруның гомуми нигезләмәләре

4.1. Тикшерү документар контроль һәм (яисә) сәүдә объектын (территориясен) күчмә тикшерү рәвешендә планлы яисә планнан тыш тикшерү уздыру турында Министрлык боерыгы (алга таба – тикшерү уздыру турында боерык) нигезендә үткәрелә.

4.2. Тикшерү үткәрү өчен Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан

Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы муниципаль районнары, муниципаль һәм шәһәр округлары администрацияләре вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин.

4.3. Тикшерү үткәрү турындагы боерыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

– тикшерүне гамәлгә ашыручы Министрлык вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм вазыйфасы;

– тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенең тулы реквизитлары (планлы тикшерү очрагында планлы тикшерүләр уздыру планына туры килә), шулай ук сәүдә объектының (территориянең) исеме һәм адресы;

– тикшерү төре – планлы яки планнан тыш тикшерү;

– тикшерү рәвеше – документар контроль һәм (яки) сәүдә объектын (территориясен) урынга барып тикшерү;

– тикшерү вакыты, башлау датасы һәм тикшерүне тәмамлау датасы.

4.4. Тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә аны үткәрү турында хәбәр (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта), шулай ук әлеге Тәртипнең 5.3 һәм 6.2 пунктларында билгеләнгән срокларда тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе җибәрелә.

4.5. Тикшерү уздыру турында хәбәр, тикшерү уздыру турында боерыкның күчермәсен теркәп, әгәр мондый адрес Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, тапшырылуы турында хәбәр белән заказлы почта аша сәүдә объектының (территориянең) урнашкан урыны адресына һәм/яисә сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенең электрон почтасы адресына яки башка үтемле ысул белән җибәрелә.

Моннан тыш, күрсәтелгән документлар:

– Министрлыкта мондый затлар турында мәгълүмат (вәкаләтләрен раслаучы документлар белән) булган очракта, сәүдә объекты (территория) хокук иясенең вәкаләтле вәкиленә югарыда санап үтелгән ысуллар белән күчермәләрдә җибәрелә ала;

– Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан аңа карата тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә тапшырыла яисә сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенең вәкаләтле вәкиленә яки сәүдә объекты (территориянең) җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка күчермәләрдә тапшырыла, шул ук вакытта Министрлыкның вазыйфаи заты аларның алынуы турында имзалы язу алырга тиеш.

4.6. Кирәк булган очракта, Министрлык әлеге Тәртипнең 4.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән бер үк вакытта тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе адресына тикшерү үткәрү өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлеген (алга таба – документлар (мәгълүмат) исемлеге) җибәрә.

Документлар (мәгълүмат) исемлеге ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе Министрлыкта саклана.

4.7. Исемлектә күрсәтелгән документлар (мәгълүмат) тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиле

тарафыннан тикшерү башланган көннән дә соңга калмыйча Министрлыкка мөһер куелган (ул булган очракта) һәм сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиленең имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырылырга тиеш.

4.8. Тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиле аның адресына җибәрелгән документлар (мәгълүмат) исемлеге нигезендә документларны (мәгълүматны) тапшырмаган очракта, документларны (мәгълүматны) документлар (мәгълүмат) исемлегендә күрсәтелгән срокны бозып тапшырганда, дөрес булмаган документлар (мәгълүмат) тапшырганда, әлеге фактлар тикшерү актында теркәлә.

4.9. Тикшерү уздырганнан соң, хокук бозулар ачыкланган очракта, сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклануын тәэмин итү һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын камилләштерү турында тәкъдимнәр җибәрелә.

## 5. Планлы тикшерүне оештыру һәм уздыру

5.1. Планлы тикшерү Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры (алга таба – Министр) боерыгы рәвешендә расланган план нигезендә өч елга бер мәртәбә гамәлгә ашырыла һәм сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклану торышын билгеләү һәм тикшерүләр барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар эшләү мәсьәләсендә документар контроль ясау яисә урынга барып тикшерү рәвешендә үткәрелә.

5.2. Планлы тикшерү уздыру турында боерык планлы тикшерү уздыру датасы башланганчы 20 календарь көннән дә соңга калмыйча чыгарыла.

5.3. Тикшерү уздыру турында хәбәр, шулай ук тикшерү уздыру турында боерык күчермәсе һәм, кирәк булган очракта, тикшереп тору өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлеге, аны үткәрү башланганчы 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 4.5 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән сәүдә объектының (территориянең) урнашкан урыны адресына җибәрелә.

5.4. Планлы тикшерү үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш.

## 6. Планнан тыш тикшерүне оештыру һәм уздыру

6.1. Планнан тыш тикшерүләр документлар буенча контроль яисә урынга барып тикшерү рәвешендә үткәрелә:

а) планлы тикшерүләр үткәрү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне тикшереп тору максатларында;

б) сәүдә объектын (территориясен) урынга чыгып тикшерү кирәклеге турында Министр карар кабул иткән очракларда;

в) сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне үтәмәүгә һәм вазыйфаи затларның, органнарның һәм оешмаларның

сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә карата гамәл кылмавына мөрәҗәгатьләр (гаризалар) кергәндә.

6.2. Тикшерү уздыру турында хәбәр, шулай ук тикшерү уздыру турында боерык күчермәсе һәм, кирәк булган очракта, контроль уздыру өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлеге сәүдә объекты (территориясе) урнашкан урын адресына аны үткәрү башланганчы кимендә 24 сәгать алдан әлеге Тәртипнең 4.5 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән җибәрелә.

6.3. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган (аноним) мөрәҗәгатьләр (гаризалар) планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

6.4. Планнан тыш тикшерү үткәрү рәвеше (документар контроль яисә урынга барып тикшерү) мөрәҗәгатьтә (гаризада) бәян ителгән белешмәләргә бәйле рәвештә билгеләнә.

6.5. Мөрәҗәгатьтә (гаризада) куелган сорауларның асылы буенча Министрлык «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда язма җавап бирә.

6.6. Планнан тыш тикшерү үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш.

## 7. Документар контроль рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне оештыру

7.1. Документар контроль рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр Министрлык урнашкан урында үзенә карата тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенең Министрлык карамагында булган документлары һәм материаллары, кирәк булганда дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан алынган белешмәләр һәм документлар, шулай ук Тикшереп тору өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлеге нигезендә үзенә карата тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясеннән, аның вәкаләтле вәкиленнән алынган белешмәләр һәм документлар буенча үткәрелә.

7.2. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр барышында документар контроль рәвешендә тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиле тапшырган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар ачыкланган очракта яисә бу документлардагы белешмәләрнең Министрлыктагы документлардагы белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, яки мәгълүматлар җитәрлек түгел икән, бу хакта мәгълүмат, ике эш көне эчендә, әмма тикшерү тәмамлану датасына бер көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә кирәкле аңлатмалар бирүне һәм, элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документлар булган очракта, аларны тапшыруны тәкъдим итеп, үзенә карата тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә җибәрелә.

7.3. Тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиле Министрлыкның контроль вәкаләтләрен үтәве өчен

кирәкле белешмәләрне тапшырмаган, шулай ук аларны күрсәтелгән вакытта тапшырмаган яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшырган очракта, әлеге фактлар тикшерү актында теркәлә.

7.4. Документар контроль рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерү барышында сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклану торышын билгеләү, планлы тикшерүләр барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне тикшереп тору мөмкин түгел икән, тикшерү үткәрүче вазыйфаи зат тикшерү актында сәүдә объектына (территориягә) карата күчмә тикшерү рәвешендә планнан тыш тикшерү уздыру кирәклеге турында нәтиҗә ясый.

## 8. Күчмә тикшерү рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр оештыру

8.1. Күчмә тикшерү рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр сәүдә объектының (территориянең) фактта урнашкан урыны буенча үткәрелә.

8.2. Тикшерү барышында:

– сәүдә объектының (территориясенең) террорчылыктан саклану торышы буенча тикшерү үткәрелә;

– объектның (территориянең) категориясен исәпкә алып, сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклану дәрәҗәсен арттыру буенча өстәмә чаралар, шулай ук күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру сроклары билгеләнә;

– террорчылыктан саклануны тәэмин итү буенча оештыру-боеру документлары тикшерелә.

8.3. Күчмә тикшерү рәвешендә тикшерү үткәрү барышында тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе, аның вәкаләтле вәкиле тапшырган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар ачыкланган очракта, яисә бу документлардагы белешмәләрнең Министрлыктагы документлардагы белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, яки белешмәләр җитәрлек түгел икән, һәм әлеге документлар башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе адресына яисә аның вәкаләтле вәкиленә карата Тикшереп тору өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлеге төзелә.

8.4. Тикшереп тору өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлеге ике нөсхәдә рәсмиләштерелә һәм Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан имзалана.

8.5. Тикшереп тору өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлегенең бер нөсхәсе тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә яисә аның вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхәдә әлеге зат, имза куеп һәм фамилиясен, вазыйфасын һәм аны алу датасын күрсәтеп, таләпне алу турында тамга куя.

8.6. Тикшереп тору өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) исемлегендә контрольне гамәлгә ашыру максатына ирешү өчен кирәкле документлар санала.

8.7. Таләп ителә торган документлар һәм мәгълүмат күрсәтелгән документны алганнан соң бер эш көненнән артмаган вакытта, әмма тикшерү тәмамланганчы 2 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

8.8. Кирәк булган очракта, урынга барып тикшерү рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләрдә катнашучы вазыйфаи затлар һәм башка затлар үзләренә күчермәләрдә тапшырылган документларның төп нөсхәләре белән танышырга хокуклы.

8.9. Министрлыкның вазыйфаи затының һәм тикшерү уздыруга җәлеп ителүче вазыйфаи затларның һәм белгечләрнең тикшерү башкарыла торган сәүдә объекты (территория) территориясенә яисә бинасына керүенә комачаулаган очракта, тиешле акт төзелә (әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта). Акт Министрлыкның вазыйфаи заты, шулай ук тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалана.

8.10. Тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе, аның вәкаләтле вәкиле күрсәтелгән актка имза салудан баш тарткан очракта, анда тиешле язу теркәлә.

8.11. Министрлыкның вазыйфаи заты күчмә тикшерү рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәргәндә, тикшерү башкарыла торган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясеннән яисә аның вәкаләтле вәкиленнән тикшерү барышында барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча, шул исәптән аны үткәрү өчен кирәкле документлар булмау факты буенча да, белешмәләр һәм мәгълүматлар алырга хокуклы. Күрсәтелгән аңлатмаларны тапшырудан баш тарткан очракта, тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

## 9. Контроль нәтиҗәсен рәсмиләштерү

9.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлыкның вазыйфаи заты тикшерү акты төзи (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта).

9.2. Тикшерү актында күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы һәм урыны;

2) тикшерүне гамәлгә ашырган органның – Министрлыкның исеме;

3) тикшерү уздыру өчен нигез булып торган Министрлык боерыгының датасы һәм номеры;

4) Министрлыкның вазыйфаи затының, тикшерүдә катнашучы оешмаларның вазыйфаи затларының һәм хезмәткәрләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм вазыйфасы;

5) тикшерү үткәрелгән сәүдә объектының (территориясенең) исеме һәм адресы;

6) тикшерү үткәрелә торган сәүдә объекты (территориясе) хокукына ия булучының тулы реквизитлары;

7) тикшерү вакыты, тикшерүне башлау һәм тәмамлау датасы һәм аны үткәрү урыны;

8) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән ачыкланган хокук бозулар турында белешмәләр, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча тәкъдим ителә торган чаралар;

9) тикшерү үткәрелә торган сәүдә объектының (территориясенең) хокук иясенең яисә тикшерү үткәргәндә шунда булган аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яисә танышудан баш тартуы турында белешмәләр.

9.3. Тикшерү актының битләре номерлана.

9.4. Тикшерү актына тикшерү үткәргән Министрлыкның вазыйфаи заты кул куя.

9.5. Тикшерү акты ике нөсхәдә рәсмиләштерелә һәм танышу өчен аңа карата тикшерү башкарылган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә, аның вәкаләтле вәкиленә тапшыру турында тамга белән тапшырыла.

9.6. Тикшерүдә катнашучы вазыйфаи зат яисә оешма хезмәткәре үзенең аерым фикерен әйтергә хокуклы, ул аны ирекле язма формада яза һәм тикшерү материалларына теркәп бара.

9.7. Тикшерү актына тикшерү нәтиҗәләренә бәйле материаллар, документлар теркәлергә мөмкин.

9.8. Коммерция, хезмәт сере, закон белән саклана торган башка сер булып торучы белешмәләр булган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәгән килеш рәсмиләштерелә.

9.9. Тикшерү акты тикшерү тәмамланганнан соң җиде эш көне эчендә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуларның берсе аңа имза салынган көннән алып өч эш көне эчендә аңа карата тикшерү башкарылган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә, аның вәкаләтле вәкиленә танышу турында яисә танышудан баш тарту турында язу имзалатып тапшырыла.

9.10. Тикшерү башкарылган сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү актын алудан баш тарткан очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты:

а) тикшерү актында тиешле тамга ясый.

б) әгәр мондый адрес Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, киләсе эш көне дәвамында сәүдә объекты (территориясе) урнашкан адрес буенча тапшырылуы турында хәбәр белән заказлы почта юлламасы итеп һәм/яисә сату объектының (территориянең) хокук иясенең электрон почта адресы буенча яки сәүдә объекты (территориясе) урнашкан адрес буенча теләсә нинди башка үтемле ысул белән

тапшыру турында хәбәр белән заказлы почта юлламасы итеп тикшерү актын җибәрә, ул Министрлыкта саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә.

9.11. Сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе, тикшерү актында бәян ителгән нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынган көннән алып җиде эш көне эчендә тикшерү актына карата язма рәвештә Министрлыкка каршылык белдерергә хокуклы. Шул ук вакытта сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе мондый каршылыкларның нигезлелеген раслый торган документларны терки. Язма каршылыклар һәм мондый каршылыкларның нигезлелеген раслаучы документлар Министрлык тарафыннан тикшерү материалларына теркәп куела.

Сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенең тикшерү актына каршы килүе Министрлык тарафыннан җиде эш көне дәвамында карала. Күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә Министрлык тарафыннан Министрлык тарафыннан тикшерү актына каршылыкларны карау нәтиҗәләре турында язма хәбәр җибәрелә.

9.12. Тикшерү уздырганнан соң, хокук бозулар ачыкланган очракта, сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә сәүдә объектының (территориянең) террорчылыктан саклануын тәэмин итү һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын камилләштерү турында Министрга тәкъдимнәр җибәрелә.

9.13. Министрлык ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, җыелма мәгълүмат әзерләүне һәм уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) доклад тапшыруны тәэмин итә.

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибенә 1 нче кушымта

________________________________

(сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе исеме, адресы)

Планлы (планнан тыш) тикшерү уздыру турында хәбәр

Сәүдә объектларының (территорияләрнең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм сәүдә объектының (территориянең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешенә тиешле тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Сезгә 20____ елның «__» __________ башлап 20____ елның «__» __________ буенча документар контроль һәм (яисә) сәүдә объектын (территориясен) урынга барып тикшерү рәвешендә планлы (планнан тыш) тикшерү уздырылуы турында хәбәр итә

________________________________________________________________,

(сәүдә объектының (территориянең) исеме,

урнашкан адресы:

________________________________________________________________

________________________________________________________________,

(сәүдә объектының (территориясенең) адресы)

Оештырыла торган тикшерү белән бәйле мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы вәкиленә мөрәҗәгать итәргә

________________________________________________________________.

(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы, телефон номеры, электрон почта адресы)

Кушымта: 1. Тикшерү үткәрү турында Министрлык боерыгы __ биттә, 1 нөсх.

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибенә 2 нче кушымта

________________________ «___» _____________ 20___ ел.

**Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы**

**Сәүдә объектының (территориясенең) террорчылыктан саклануын планлы (планнан тыш) тикшерү уздыру турында акт**

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________,
(объектның (территориянең) тулы һәм кыскартылган исеме (җәяләрдә)

_______________________________________________________________________________
(тикшерү уздыру өчен нигез булып торган Министрлык боерыгы реквизитлары)

урнашкан адресы: ______________________________________________________
_______________________________________________________________________________

**Комиссия составы:**

Объект (территория) вәкиле_____________________________________________
_______________________________________________________________________________
(вазыйфасы, ФИА (соңгысы – булган очракта) тулысынча, элемә өчен мәгълүматлар)

ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы вәкиле ________________________________
(вазыйфа)

куркынычсызлык һәм террорчылыктан саклау бүлеге
_______________________________________________________________________________
(ФИА (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

ТР буенча РФ Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте вәкиле ______________________________________________________________
(вазыйфа)

_______________________________________________________________________
(званиесе)

_______________________________________________________________________
(ФИА (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

Башка оешмалар вәкилләре (булган очракта): ____________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(вазыйфасы, ФИА (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

Тикшерү вакыты: ________________________________________________________
(тикшерүне башлау һәм тәмамлау даталары һәм аны үткәрү урыны)

**Гомуми белешмәләр:**

Сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе: ______________________________
_______________________________________________________________________

Объект (территория) җитәкчесе: __________________________________________
_______________________________________________________________________
(вазыйфасы, ФИА (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

Объектның (территориянең) террорчылыкка каршы иминлеге өчен җаваплы зат:
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(вазыйфасы, ФИА (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

**Объектның (территориянең) инженер-техник ныгытылуы:**

1. Киртәләр: _____________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(характеристика)

2. Керү капкалары, капкалар саны: ______________________________________
_______________________________________________________________________
(характеристика)

3. Видеокүзәтү системасы, видеоязма системасы булу: ____________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(видеокамераларның саны (тышкы һәм эчке), видеомәгълүматны саклау вакыты, эшкә сәләтлелеге күрсәтелә)

4. Хәвефле сигнализация төймәсе: ___________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(кая чыгарыла, саны, булуы, эшкә сәләтлелеге)

5. Сак сигнализациясе: ____________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(кая чыгарыла, техник хезмәт күрсәтү, эшкә сәләтлелек)

6. Янгын сигнализациясе: ___________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(кая чыгарыла, эшкә сәләтлелек)

7. Керү мөмкинлеген контрольдә тоту һәм идарә итү системасы (СКУД) _________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(характеристика, техник хезмәт күрсәтү, эшкә сәләтлелек)

8. Стационар һәм кулдан металл эзләгечләр булу: __________________________
____________________________________________________________________________
(стационар металл эзләгечләр саны, урнаштыру урыннары (булган очракта)

9. Саклауның башка инженер-техник чаралары: _____________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(видеодомофон, шлагбаум, интроскоплар, тараннарга каршы җайланмалар, тизлекне киметү чаралары һ.б.)

## Объектны (территорияне) физик саклау чаралары

1. Объектны (территорияне) физик саклау: ____________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(Шәхси сак, каравылчы, вахтер яки башка төрле; алмашка килүче хезмәткәрләр саны)

2. Контроль-үткәрү пунктлары (сак постлары) саны: _________________
____________________________________________________________________________
(характеристика, бинага кергәндә һәм объектка якын территориягә кергәндә)

3. Пост һәм сак урыны булу _________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(бар/юк, характеристика, урнашу урыны (кат))

4. Физик саклау турында өстәмә мәгълүмат (кирәк булганда)
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________

## Объектта документлар булу (әйе/юк):

| үткәрү режимы буенча | объектлар хезмәткәрләре белән АТЗ буенча инструктаж үткәрү буенча | АТЗ буенча өйрәнүләр (тренировкалар) үткәрү буенча | АТЗ буенча күрсәтмә белешмәлекләр булуы (мәгълүмат стендлары) | теракт куркынычы булганда хезмәткәрләрне, укучыларны һәм башка затларны эвакуацияләү тәртибе буенча | мәгълүмати куркынычсызлык чараларын гамәлгә ашыру буенча |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

## Объектның (территориянең) террорчылыктан саклануының иминлек паспорты

1. Куркынычсызлык паспорты__________________, расланган _________________,
(бар/юк) (раслау датасы)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең _____ номерлы карары нигезендә эшләнгән.
2. Бирелгән куркынычлык категориясе _______
3. Куркынычсызлык паспортында күрсәтелгән мәгълүматларның тикшерү вакытына фактагы мәгълүматларга туры килүе ________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
(туры килә/туры килми; әгәр туры килмәсә, төгәл нәрсә)

4. Куркынычсызлык паспортында күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү: ___________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
(нәрсәне бетерелгәнен күрсәтергә; әгәр бетерелмәгән булса, куркынычсызлык паспортында күрсәтелгән бетерү срогын күрсәтергә кирәк)

**Объектның (территориянең) террорчылыктан саклануын планлы (планнан тыш) тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләр:**
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**Объект (территория) үзенчәлекләрен исәпкә алып, өстәмә мәгълүмат:** ______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**Тәкъдимнәр:**
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының вазыйфаи заты:
______________________________________________________________________
(ФИА (соңгысы – булган очракта), имза, дата)

Тикшерүдә катнашучы оешмаларның акт белән танышкан вазыйфаи затлары һәм белгечләре:

1. ____________________________________________________________________
(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, оешма, имза, дата)

2. ____________________________________________________________________
(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, оешма, имза, дата)

Тикшерү акты белән таныштым

______________________ 20__ ел.

______________________________________________________________________
(сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе, аның вәкаләтле вәкиле (ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, вәкаләт бирүче документның реквизитлары, имза, дата)

Актның барлык кушымталары белән күчермәсен (сәүдә объектының(территориянең) тикшерелә торган хокук иясеннән алынган документлардан тыш) алдым:

______________________ 20___ ел.

____________________________________________________________

(сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе, аның вәкаләтле вәкиле (ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, вәкаләт бирүче документның реквизитлары, имза)

Сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенең, аның вәкаләтле вәкиленең, сәүдә объекты (территориясе) җитәкчесенең акт алудан/актны имзалаудан баш тартуы турында тамга

____________________________________________________________

(Тикшерү уздырган вазыйфаи затларның һәм белгечләрнең ФИА (соңгысы – булган очракта), имзалар)

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибенә 3 нче кушымта

Вазыйфаи затның территориягә (бинага) керүенә каршылык күрсәтү турында акт

______________________________ ______________________________
(төзү урыны) (төзү датасы һәм вакыты)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм сәүдә объектының (территориянең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешенә тиешле контрольлекне гамәлгә ашыру максатларында, сәүдә объектын (территориясен) урынга барып тикшерү рәвешендә планлы (планнан тыш) тикшерү уздырганда

________________________________________________________________________,
(сәүдә объектының (территориянең) исеме,

урнашкан адресы:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________,
(сәүдә объектының (территориясенең) адресы)

сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе
________________________________________________________________________,
(юридик зат: исеме, ИНН; шәхси эшкуар: ФИА (соңгысы – булган очракта), ИНН; физик зат: ФИА (соңгысы – булган очракта), туу датасы)

тикшерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларга һәм белгечләргә
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, оешма, тикшерүдә катнашуга җәлеп итү турындагы документның реквизитлары)

сәүдә объекты (территория) территориясенә (бинасына) керүне тоткарлады.

Сәүдә объектының (территориянең) хокук иясенә күчмә тикшерү рәвешендә планлы (планнан тыш) тикшерү уздыру турында «__» ______________ 20__ ел, № _____________.

______________________________________________________________________________.
(өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Планлы (планнан тыш) тикшерү уздырган вазыйфаи зат:
______________________________________________________________________________.
(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, имза, дата)

Тикшерүдә катнашучы акт белән танышкан вазыйфаи затлар һәм оешмалар вәкилләре:

1. _________________________________________________________________;
(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, имза, дата)

2. _________________________________________________________________.
(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, имза, дата)

Сәүдә объектының (территориянең) хокук иясе яисә аның вәкаләтле вәкиле*:
______________________________________________________________________________.
(ФИА (соңгысы – булган очракта), вазыйфа, вәкаләт бирүче документның реквизитлары, имза, дата)

* Имзадан баш тарткан очракта «имзадан баш тартты» дигән язу теркәлә, аның астында планлы (планнан тыш) тикшерү уздырган вазыйфаи затлар имза куя.